Казан федераль УНИВЕРСИТЕТЫ
Алабуга ИНСТИТУТЫ

татар студентлары газетасы

# шәкерт

**Шәкерт булмаган – остаз булмас!**

Гыйнвар-май ’2022

# Филология һәм тарих бүлеге яңалыклары

## XI Халыкара тюркологик конференция

«Россиядә Ислам: тарих, мәдәният, икътисад» дип исемләнгән XI Халыкара тюркологик конференция 2022 елның 13 маенда Казан федераль университетының Алабуга институтында узачак. Конференция Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам диненең рәсми кабул ителүенә 1100 ел тулуга һәм Россия халыкларының мәдәни мирасы елына багышланган.

Конференциянең төп максаты – Россия территориясенә Исламның үтеп керүе һәм таралу тарихын; Евразия халыклары мәдәниятен һәм икътисадын берләштерүдә, шулай ук тел, әдәбият, төрки этнослар фольклорын формалаштыруда һәм үстерүдә аның тоткан ролен тикшерү.

Чараны уздыру барышында тикшерелә торган төп юнәлешләр:

- төрки халыкларда Ислам һәм дини күзаллаулар;
- төрки халыкларның археологиясе, тарихы һәм матди мәдәнияте;
- төрки халыкларның фольклоры һәм әдәбияты;
- төрки халыкларның топонимикасы һәм ономастикасы;
- хәзерге төрки тел белеменең актуаль проблемалары;
- төрки телләр һәм әдәбият укытуда инновацияләр;
- лингвокультурология һәм тәрҗемә проблемалары;
- Ислам икътисады моделе һәм ислам дөньясын үстерүдә төрки халыкларның роле.



## Күңелле очрашулар

2022 елның март аенда КФУның Алабуга институтында күренекле әдипләр белән очрашулар узды. Филология һәм тарих бүлегенең «Фән җилкәннәре» студентлар фәнни-әдәби түгәрәге әгъзалары прозаик, Гаяз Исхакый, Абдулла Алиш, Габдулла Тукай исемендәге премияләр лауреаты, филология фәннәре кандидаты, ТР Язучылар берлегенең Чаллы бүлекчәсе җитәкчесе Факил Сафин һәм татар композиторы, артист, прозаик, язучы, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТР Язучылар берлеге әгъзасы Алмаз Хәмзин белән очрашты.

Студентлар һәм фәнни түгәрәк әгъзалары язучыларның иҗаты белән якыннанрак таныштылар. Факил Сафин кайбер әсәрләрнең (мәсәлән, «Соңгы көз», «Гөлҗиһан») барлыкка килү тарихы белән уртаклашты. Алмаз Хәмзин исә үзенең моңлы тавышы белән студентларны җыр дөньясына алып керде. Язучылар шулай ук студентларның күпсанлы сорауларына җавап бирделәр.



## Студентларыбыз ирешкән уңышлар

### *“Яшә һәм чәчәк ат, туган тел» бәйгесе*

22 апрельдә Алабуга шәһәрендә үткәрелгән Россия халыкларының сәнгате һәм мәдәни мирасы елына багышланган Бөтенроссия нәфис сүз бәйгесе “Яшә һәм чәчәк ат, туган тел» нәтиҗәләре буенча бүләкләү тантанасы булып узды. Бәйгене Алабуга шәһәренең “Барс” Яшьләр үзәге оештырды. КФУның Алабуга институты татар бүлегенең 4 һәм 5 курс студентлары бу бәйгедә призлы урыннарны яуладылар. Зиннатова Айсинә 1 призлы урын өчен диплом һәм сертификат белән бүләкләнде, Антонова Диана 2 призлы урын өчен диплом белән бүләкләнде, Камалова Зөлфия мактау хаты алды.



## «Ана теле-2022» бәйгесе

КФУның Алабуга институты татар бүлеге студентлары – Башкортостанның Уфа шәһәрендә үткәрелгән «Ана теле-2022» XIV Бөтенроссия студентларның педагогик осталык бәйгесендә җиңүчеләр булдылар.

«Ана теле» конкурсы талантлы студентларны – булачак татар теле һәм әдәбияты укытучыларын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм бүләкләү, туган тел һәм әдәбият укытучысы һөнәренең абруен күтәрүгә юнәлдерелгән.

Конкурс нәтиҗәләре буенча татар филологиясе кафедрасы галимнәре җитәкчелегендә студентлар призлы урыннарны яуладылар. Евдокимова Алёна I дәрәҗә диплом белән бүләкләнде (җитәкчесе – филология фәннәре кандидаты, доцент Габидуллина Ф.И.), 4 курс студентлары Зиннатова Айсинә, Камалова Зөлфия 3 дәрәҗә дипломнар белән бүләкләнделәр (җитәкчеләре – филология фәннәре докторы, профессор Камаева Р.Б.), ә Марданова Розалия «Кыюлык» номинациясендә җиңүче булды (җитәкчесе – филология фәннәре кандидаты, доцент Хайруллина А.С.).



## IX Халыкара олимпиада

Татар теле һәм әдәбиятыннан IX Халыкара олимпиадада КФУның Алабуга институты татар бүлеге студенты – Әхмәтова Фәридә призер булды. Шулай ук Антонова Диана, Тимофеева Татьяна, Шафикова Зилә үз көчләрен сынап, катнашучы исемен алдылар.

Студентларыбыз дистанцион тест нәтиҗәләре нигезендә II турга үттеләр. Олимпиада 17-20 апрельдә Казан шәһәрендә үтте.

Икенче турда катнашучыларга “Минем шәҗәрәм” проектын якларга кирәк булды. Безнең студентларыбыз уңышлы чыгыш ясап кына калмадылар, ә күңелле ял итеп тә кайттылар.



## Интеллектуаль лидер – 2022

26 апрельдә Алабуга институтының актлар залында “Интеллектуаль лидер – 2022” чарасының XIV бүләкләү тантанасы узды. Бу чара – студентларның фәнни-иҗади потенциалын хөрмәтләү, зурлау чарасы. Елдан-ел фәнгә җәлеп ителгән студентларның саны арта бара, һәм бу сөенечле күренеш.

Әлеге тантанада иң яхшы фәнни мәкалә номинациясендә татар бүлегеннән түбәндәге студентлар бүләкләнде: I урын - Тимофеева Татьяна; II урын - Мөхәммәтҗанова Илзирә; III урын - Шафикова Зилә, Арсланов Илмир.



## “Өчпочмак” проекты

2021-2022 уку елында “Университет” мәктәбендә “Өчпочмак” проекты тормышка ашырылды. Татар филологиясе кафедрасы һәм татар бүлеге студентлары ярдәмендә мәктәп укучылары татар милли ризыкларының иң танылганы – өчпочмак пешерергә өйрәнделәр. Алай гына да түгел, ризык әзерләнгән арада балалар татар халык уеннары белән дә таныштылар, квестлар үттеләр. Чара ахырында балалар бик теләп өстәл артына утырып, үз хезмәтләренең җимешләрен татыдылар.

«Өчпочмак» проектының төп нәтиҗәсе – бәхетле балалар. Әмаксаты – балаларны берләштерә, аларны хезмәткә өйрәтә торган гамәли эш аша татар халкының милли традицияләренә, татар теленә булган мәхәббәтне саклап калу.

татар студентлары газетасы
шәкерт

# БӨЕК ҖИҢҮГӘ 77 ЕЛ





*Рәхмәт сезгә, исән калганнар.*
*Мәңге хәтердә һәлак булганнар...*

6 май көнне КФУның Алабуга институтында Бөек Җиңүнең 77 еллыгына багышланган бәйрәм чарасы узды. Көн дәвамында профессор-укытучылар составы һәм югары уку йорты хезмәткәрләре ветераннарга һәм Бөек Ватан сугышы геройларына җылы сүзләр әйттеләр, ә студентлар һәм «Университет» мәктәбе укучылары бию һәм вокал номерларын һәм театраль куелышларны башкардылар.

Төп кунаклар – югары уку йорты һәм Алабуга муниципаль районы ветераннары. Институт каршындагы мәйдан Бөек Җиңүнең 77 еллыгына багышланган концерт мәйданчыгы булды. Институт бакчасында поход палаткалары, кыр кухнясы куелды, Дмитрий Стахеев һәйкәленнән ерак түгел «Университет» мәктәбе укучылары парад сәгатен көттеләр, ә юлның машиналар йөрү өлешендә «Волга» һәм Т-34 танкларыннан механикалаштырылган колонна торды.

Шулай ук Алабуга институты студентлары һәм «Университет» мәктәбе укучылары хәрби эстафетада катнаштылар. Ел саен Бөек Җиңү көнен бәйрәм итү кысаларында Физик культура һәм тормыш иминлеге теориясе һәм методикасы кафедрасы укытучылары "Без-җиңүчеләр оныклары!" дип исемләнгән эстафета уздыралар. Быел спорт ярышларында 6 команда катнашты, алар арасында югары уку йорты студентлары һәм «Университет» мәктәбе вәкилләре дә бар иде. Нәтиҗәләр түбәндәгечә булды: беренче урынны психология һәм педагогика бүлеге командасы яулады, икенче урынны «Университет» мәктәбе командасы, өченче урынны икътисад һәм юридик фәннәр командасы алды.

Җиңү көненә багышланган бәйрәм чаралары Университет мәйданы янында Үлемсез полк белән тәмамланды. Укучылар һәм укытучылар, кулларына бабайларының, әтиләренең, туганнарының портретларын тотып, һәлак булучыларны бер минут тынлык белән искә алдылар, һәм йомгаклау рәвешендә канәфер чәчкәләре салынган кәрҗинне Хәтер мәйданына салдылар.

# "КАУРЫЙ КАЛӘМ" БӘЙГЕСЕ

Татар филологиясе кафедрасы КФУның Алабуга институты студентлары һәм Университет мәктәбе укучылары өчен "Каурый каләм" бәйгесе уздырды. Бәйге студентларда, укучыларда татар телен, әдәбиятын, тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә кызыксыну уяту; укучыларда ватанпарвәрлек, жаваплылык сыйфатлары тәрбияләү өчен уңай шартлар тудыру максаты белән үткәрелде.

"Каурый каләм" бәйгесе нәтиҗәләре

Студентлар арасында "Шигырь" номинациясе буенча җиңүчеләр:

1 урын – Гилязов Азат Ленарович (9112 нче төркем студенты) "Солдат ята ап-ак карда..." шигыре.

2 урын – Камалова Зөлфия Фәниловна (8112 нче төркем студенты) "Туган тел" шигыре.

3 урын – Мөхәммәтҗанова Илзирә Илгизовна (7112 төркем студенты) "Илемә тынычлык телим!" шигыре.

Студентлар арасында "Публицистика" номинациясе буенча җиңүчеләр:

1 урын – Зиннәтова Айсинә Илһамовна (8112 нче төркем студенты) "Егерме елдан соң татар теленең торышы нинди булыр?"Эссе.

2 урын – Нуриева Резеда Рөстәмовна (9112 нче төркем студенты) "Сызылып язгы таң ата". Эссе.

3 урын – Иванова Лиана Валерьевна (9112 нче төркем студенты) "Гаилә бәхетенең сере бармы?" Эссе.

Студентлар арасында "Хикәя"номинациясе буенча җиңүчеләр:

1 урын – Фаррахова Ләйсән Флеровна (9112 нче төркем студенты) "Аяусыз сугыш" хикәясе.

2 урын – Николаева Ольга Николаевна (7112 нче төркем студенты) "Сугыш афәте" хикәясе.

3 урын – Саляхова Нурфия Миннегабдуловна"Беренче мәхәббәт" хикәясе.

"Университет" мәктәбе укучылары арасында җиңүчеләр:

1 урын – Закирова Амира (6б сыйныфы укучысы) "Тукай-үлемсез" шигыре

2 урын – Нуретдинова Эльвина(3б сыйныфы укучысы) "Әнием гөлләре" шигыре

3 урын – Федорова Кристина (8 б сыйныфы укучысы) "Каһарманлык" хикәясе

## Аяусыз сугыш

Сугыш... Иң куркыныч, шомлы, бар кешелекне дер селеккән сүзләрнең берсе бу. 1941 елда ул һәр кешенең өенә бәреп кергән. Миллионлаган кешеләрнең гомерен өзгән, күпме балаларны ятим иткән, аналарны тол калдырган, меңләгән шәһәрләрне җимергән, гөрләп торган авылларны юкка чыгарган бит ул. Бөек Ватан сугышы тәмамланганга бик күп еллар үтсә дә, аның хатирәләре әле дә күңелләргә шомлы хисләр өстәп торалар.

Бөек Ватан сугышы халыкның батырлыгын, Туган илгә бирелгәнлеген, чиксез мәхәббәтен, төрле миллләт халыкларының бердәмлеген күрсәтә. Ил өчен авыр сынау көннәрендә халкыбыз фидакарьлеген, курку белмәс көчен күрсәтте. Нәкъ шуның нәтиҗәсендә 1418 көн һәм төн барган бу мәхшәрдән халкыбыз җиңүче булып чыкты.

Бу җиңүдә тылда калган хатын-кызлар һәм балаларның да роле зур. Алар сугышка киткән ир-атларның эш урынына басалар, армый-талмый көнетөне эшлиләр. Ничек кенә авыр булса да, түзәләр, бирешмиләр, җиңү өчен бар көчләрен куялар. Сугыш елларында булган авырлыклар хакында миңа әбием дә бик еш сөйли. Аның күзеннән тамган һәр күз яшеннән бу елларның ничек дәһшәтле, комсыз булуы күренә дә инде. Сугыш вакытында, сугыштан соңгы авыр елларда күргән михнәтләрне өлкәннәребез һаман да онытмый. Илебез, аның халкы өчен сугыштан соңгы берничә ел да бик газаплы була әле. Җимерек авыл-шәһәрләрне, завод-фабрикаларны, колхозларны торгызу өчен бик күп көч таләп ителә. Өстәвенә, ул елларда да ачлык-ялангачлык хөкем сөргән була әле.

Чыннан да, сугыш бик куркыныч, аяусыз ул. Бүгенге тынычлык өчен әби-бабаларыбызга мең рәхмәт әйтәсе килә. Миллионлаган кеше гомере бәрабәренә яулап алынган җиңү таңы атканга быел җитмеш җиде ел була. Санаулы гына калган ветераннарга тыныч картлык, якыннарының игелекләрен күреп, рәхәт гомер итүләрен телим. Илебез күге һәрвакыт шулай тыныч, ә кешеләр бәхетле булсын иде! Безгә дә, киләчәк буыннарга да мондый коточкыч сугыш афәтен күрергә язмасын!

*Фаррахова Л.Ф. (9112нче төркем)*



## Солдат ята ап-ак карда...

Солдат ята ап-ак карда
Әнисенә хат яза.
"Әнием, бар да яхшы!" - ди
Үзендә тирән яра.

Кайтам инде тиздән, әнкәй,
Чәеңне куеп син көт
Минем өчен борчылма син
Күз яшьләреңне дә сөрт.

Без җиңәрбез, мин ышанам
Инде күп калмады, тиздән бетә
Шул вакытта кинәт арттан килеп
Немец пычак белән төртә.

Солдат кинәт кала катып,
Күзләр томанлана, Кан тама
Газиз әнкәсенә җибәрәсе хатын
Явыз фашист күтәреп ала.

Карый, берни аңламый
Ташлый хатны утка.
Солдат соңгы сулышын ала,
Соңгы сүзен әйтә: тукта.

Таңнар ата, күккә кояш чыга,
Күрмәс солдат моңы үзе.
Янмый калган, кызыл карда ята
Бары "әнием" сүзе.

*Гилязов Азат (9112нче төркем)*

**“КАУРЫЙ КАЛӘМ” бәйгесеннән студентлар һәм укучылар иҗаты**

# Егерме елдан соң татар теленең торышы нинди булыр?

Егерме елдан соң татар телен укытуның торышы бик яхшы булыр, дип өметләнеп яшим мин. Ни өченме? Беренчедән, ул вакытта Татарстаныбызда татар телен яхшы белүчеләргә ихтыяҗ бик зур булачак. Ул фән, техника, сәнәгать, мәдәният, әдәбият һәм башка өлкәләрдә туачак. Икенчедән, татар теленә туган тел һәм икенче дәүләт теле буларак та хөрмәт уяначак. Өченчедән, татар теленбелү чит җирләрдә яшәүче төрки халыклар белән аралашуны, аңлашуны, алар белән дустанә мөнәсәбәтләрне тагын да арттырачагын бик күпләр аңлаячак. Мин бу мисалларны дүртенчедән, бишенчедән ...дип дәвам итә алыр идем. Әйе, һичбер икеләнүсез әйтәм бу сүзләрне, чөнки минем туган телем ЮНЕСКО тарафыннан кабул ителгән 14 иң камил тел арасында. Татар телендә шигырь, җыр тыңлаган кешеләр аның никадәр үзенчәлекле булуы хакында фикерләре, хисләре белән уртаклашалар.

Татар телен белүчеләргә ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен яхшы мөгаллимнәр дә кирәк булачак, диярсез. Ышаныгыз, үз эшенең остасы булган укытучылар да бар бүгенге көндә. Аларга илһам биреп торырга, хезмәтләрен бәяли белергә, кирәк чакта ярдәм кулы гына сузарга кирәк, минемчә. Чөнки татар теле укытучысы – мәктәпнең “әнисе” ул. Мәктәптә нинди генә чара узмасын, аның башлап йөрүчесе – татар теле укытучысы. Татар мәктәпләрендә бу гомер бу шулай булган һәм булачак.

Әлбәттә, һәр заманның үз максатлары.Ул максатка ирешүдә уңышлар да, авырлыклар да булыр. Шуны онытмаска кирәк: укыту һәр заманда да теория һәм практика бәйләнешендә тормышка ашырылса гына уңышлы була. Татар телен ни өчен өйрәнергә кирәклеген аңлап укымаган укучыдан ни көтәсең?..

Үз хезмәтенә тугрылыклы булып, нинди авырлыклар килсә дә башын югары күтәреп алга баручы бүгенге көн укытучысына алмашка килүче яшьләр килерме? Шушы сорау борчыймы сезне? Күпләребез кулланмый да торган “кәһвә”, “итагать”, “фидакарь” кебек сүзләр белән аралашучы яшьтәшләремне тыңлагач, үз сөйләмемнән оялып китәм мин. Ышаныгыз, киләчәк андыйлар да, диясем килә. Бар әле, бар татар халкының өметле уллары, кызлары!

*Зиннатова Айсинә (8112нче төркем)*

---



## Туган тел

Бүген дәрес вакытында,
Бер уй керде башыма.
Нишләп икән яшь балалар
Рус теленә тартыла?

Кайдан нде яшьләр генә,
Әти-әнисәдә шул.
Әбиләргә килеп кергәч,
Беренче сүз «Здравствуй»...

Ниләр безнең телебезне
Шул дәрәҗәгә җиткергән?
Ничек икән рус теле
«модный тел»гә әверелгән?

Бер уйласаң, татар теле
Нинди камил, матур тел.
Ләкинн ишләп сүзгә күчкәч,
Без сүз әйтә алмыйбыз гел?

Миллион сүз арасыннан
Кайсы кирәк-белмибез.
Ә ниндидер чит-ят телдә
Рәхәтләнеп сөйлибез...

Төптән торып уйласаң,
Бу бик тә аянычлы хәл!
Телебезне саклар өчен
Табарга иде берәр әмәл!

Яшьләребез, картларыбыз
Татар телен үз итсен.
Сөйләшкәндә «модный тел» дип,
Сайлансын тик Туган тел!

*Камалова Зөлфия (8112 нче төркем)*

## Тукай-үлемсез

Казанга китте Тукай.
Пар атларда җилдереп.
Өйрәнәбез кечкенәдән
Туган телне иң элек.

Тукай гомере- җырлы гомер.
Иҗатында яшьлек ялкыны.
Өшетмәгән аны балачакта
Кышкы кичнең зәһәр салкыны.

Сагына Кырлай урманнары,
Сагына аны татар баласы.
Җырланмыйча калды күпме җыр,
Күпме шигырь калды язасы.

Халкың өчен иҗат иттең,
Кыска булды ләкин гомерең.
Баш иябез синең каршыңда.
Чәчәкләргә күмелә каберең.

Татар халкы өчен йолдыз булып
Балкыйсың син илем күгендә.
Безнең йөрәкләрдә, күңелләрдә,
Арабызда Тукай бүген дә!

Туган тел ул-Тукай теле,
Татарларны Тукай яшәтә.
Тукай-бөек, Тукай- үлемсез.
Тукай үлми, халык яшәсә.

*Закирова Амира (6б сыйныфы)*

## Әнием гөлләре

Алы бар, кызылы, агы
Бар түшәмгә тигәне.
Бар арада үрмәлесе,
Акча гөле дигәне.

Әниемнең иң яраткан
Шөгыле ул, белегез.
Өебез оранжереясын
Сез дә кереп күрегез!

Әнием гөлләр үстерә
Яратып,назлап,сөеп.
Матур гөлләремә карап
Һәркем соклансын диеп.

*Нуретдинова Эльвина (3б сыйныфы)*

## Эх, син, минем студент тормышым

Эх, син гади студент тормышы..
Авыр да син, ләкин күңелле.
Әллә нинди хәтирәләр белән
Баетасың безнең күңелне.

Көлдерәсең үзең, елатკалыйсың да..
Төнге йокыларны аласың.
Айлар буе тилмертәсең кайчак
Сулатмыйча авыл һавасын.

Ә кайвакыт, безне җәлләп ахры,
Ял иттереп алган буласың,
Я “автомат”, я “окно”лар белән
Күңелне дә күреп торасың.

Юк, уйлама тагын үрти диеп сине.
Карап торма алай шаккатып.
Сүзләр белән чеметсәм дә сине,
Мин бит инде болай, яратып.

Мин рәхмәтле сиңа бу тәҗрибә өчен,
Эх, син гүзәл студент тормышым.
Синең белән үткән елларымда
Киңәйде дөньяга карашым.

Нәни кызчык идем.. Шул арада
Синең белән ничек үскәнмен!
Синең белән сынауларны кичеп
Югарыга таба менгәнмен.

Эх, син матур студент тормышы.
Авыр булдың, ләкин күңелле.
Әллә нинди хәтирәләр белән
Баеттың син безнең күңелне.

Ышанасы килми: юлларыбыз шулай
Аерылыр вакыт җиткәнгә.
Сөенәм дә, ләкин шул вакытта
Моңсулык та керә күңелгә.

Алда билгесезлек. Ләкин кая гына
Илтсә дә безне язмыш юллары,
Мәңге калыр безнең күңелләрдә
Кабатланмас студент еллары.

*Мөхәммәтҗанова Илзирә, 7112 төркем*

## Шәкертләребезнең иҗат җимешләре

# Үткәннәрне әгәр белмәсәң...

Сугыш…. Кемнәрнең генә үзәген өзмәгән дә тормышын җимермәгән бу афәт. Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт, ачы күз яшьләре китергән. Ул ничә миллион кешенең гомерен өзгән, күпме баланы ятим иткән, аналарны тол калдырган… Яшь-яшь егетләр, кызлар, туган җирләрен саклау өчен, фронтка киткәннәр. Меңләгән шәһәрләр җимерелгән, җир йөзеннән гөрләп торган авыллар юкка чыккан, шау чәчәккә күмелгән бакчалар янып көлгә әйләнгән.

Бөек Ватан сугышының тынганына 75 ел вакыт үтте. Мин үзем дә, әтиәнием дә сугыш чорын күрмәдек. Бу канкойгыч сугыш турында бабамның сөйләгәннәреннән ишетеп кенә беләбез. Әгәр уйлап карасаң, утызынчы еллар фаҗигасе бер генә төбәкне дә, бер генә халыкны да, бер генә милләтне дә читләтеп узмаган. Күзгә караңгы төннәрнең берсендә Антиповларның да ишекләрен кагалар. Гадел, һәрвакыт дөреслек өчен көрәшүче әтиләрен һәм олы яшьтәге бабайларын "халык дошманнары" дигән нахак тамга белән алып китәләр. Алар үзләре дә ни сәбәпле кулга алынуларын белмичә калалар. Бетмәс-төкәнмәс сорау алулар, судсыз-нисез төрмәдән төрмәгә күчерер йөртүләр башлана. Юлларында яхшы кешеләр очрап, аларның гаепсез булуларын аңлапмы, балалар бәхетеннәнме, бер елдан аларга туган нигезләренә әйләнеп кайтырга насыйп була. Әмма балаларның сөенечле, бәхетле көннәре озакка бармый, дәһшәтле сугыш башлана. Сугышка җибәрү өчен, станциягә колхоздан атлар алып барган җиреннән газиз әтиләрен фронтка алып китәләр. Ул шул китүеннән туган нигезенә әйләнеп кайтмый, гаиләсенә "батырларча һәләк булды" дигән җаныөшеткеч хәбәр генә килеп ирешә. Кочак тулы балалары белән тол калган әнкәләре өлешенә тигән тормыш авырлыклары өлкән балалары Василий һәм 12 яшьлек бабам Семён җилкәсенә дә төшә.

1942 нче елның җәендә, Мәскәү янында каты сугышлар барган көннәрнең берсендә, 18 яшьлек Василийны да Кукмара район хәрби комиссариатына чакыртып алалар. Бу чакыру көтелмәгән хәл булмый. Моңарчы да инде

Василий, сугышка алуларын сорап, берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән була. Ул, ниһаять, үз теләгенә ирешә.

Василий Михайловичка немецлар белән очрашырга туры килми. Аны икенче сугыш учагы кабынырга торган Ерак Көнчыгышка ил чиген сакларга җибәрәләр. Абыйларыннан хәбәр бик сагындырып кына килә, чиктәге хәлләр кискенбула. Японнар Маньчжурия территориясен 1929 нчы елда ук яулап алганнар. Тәҗрибәле чик сакчылары Көнбатыш фронтына алынгач, биредә башлыча яшьләр кала. Кеше җитмәү сәбәпле, унбишәр сәгать постта булалар, аннан кайткач, оборона корылмаларын төзүдә солдатлар җилкәсенә төшә. Япония гаскәрләре еш кына чикләрне боза, төрле конфликтлар кузгата, тылга агент-диверсантлар җибәрә.

Иптәшләренең ихтирамын, командир-ларның ышанычын яулаган сержант Антипов хезмәт итүенең икенче елындаук отделение командиры була. Чик сагының остасы булып танылган Татарстан егете яшь солдатларның остазына әверелә, алар белән сугышчан осталыгы, белеме һәм тәҗрибәсе белән уртаклаша.

Абыйсын армия сафларына алгач, авыр чакта сыенып кешесе бөтенләй калмый, эне-сеңелләренең дә зур абыйлары була Семён бабам. Әниләре көне буе эштән кайтып керми. Хәлдән таеп, өйләренә кайтып егылгач та тынгылык юк – салым түләнмәгән дип, идарәгә чакыртып сүгәләр.

Бабай өлкәннәр белән берраттән, көнне төнгә ялгап, басудан көлтә ташый, колхозда нинди эшкә кушалар, шуны башкара. Әле буыннары да ныгып җитмәгән малайларга күпне күрергә, үзләре хәтле капчыкларны күтәрергә туры килә, чөнки тылда төп көчләр – бабамның яшьтәшләре һәм балалы хатыннар. Барлык җыелган икмәк фронтка солдатларга озатыла, кешеләр көздән кырда калган икмәк башакларын, өшегән бәрәңгене җыеп алып кайтып,алабута орлыгыннан ипи пешереп ашыйлар, 30-40 чакрым ераклыкта урнашкан район үзәгеннән авылга яз көне атлар һәм чаналар белән орлык ашлык ташыйлар.

1945 нче елны "хәбәрсез югалган" берничә ир-ат авылга әйләнеп кайткач, бабам, һәр көн басу капкасы янына чыгып, әтисен көтә, әмма ул кайтмый. Абыйсы Василий,сугышның төрле авырлыкларын җиңеп, сугыш тәмамланганнан соң бары 1949 нчы елда гына туган якларына әйләнеп кайту бәхетенә ирешә.

Төньяк Кытайны азат итүдә катнашкан Василий Антипов "Япониягә җиңгән өчен" медаль белән бүләкләнә. Хезмәтләрен искә алып, махсус задание үтәгәне өчен,"Иң яхшы разведчик"дигән билгегә лаек була. Шулай ук Мактау кәгазьләре дә бирелә. Хәрби часть газетасы аның турында: "Коммунист Антипов– заставадагы барлык яшь сугышчыларның остазы һәм укытучысы. Ул алар арасында зур политик аңлату эше алып бара, үзенең тәҗрибәсен һәм белемен бирә", – дип язып чыга.

Сугыштан соң бабам Семён 4 ел Румыниядә хезмәт итә. Аннан кайткач, Вятка Аланы шәһәрендәге заводта эшли, авылда "Заветы Ильича" хуҗалыгында тимерче булып, арутталуны белмичә 32 ел хезмәт куя һәм "Атказанган колхозчы" исеменә лаек була. Абыйсы Василий исә,ил чигендә торганда ук, кеше тынычлыгын сакларга, милиция работнигы булырга сүз бирә. Чыннан да, егет теләген тормышка ашыра. Башта Теләче, Саба районнарының эчке эшләр бүлегендә участок инспекторы, җинаятьчеләрне эзләү инспекторы булып эшли. 1964 нче елны Кукмара районы эчке эшләр бүлегенә каравыл начальнигы итеп күчерелә. Василий Михайлович үз эшен намус белән башкара, аның орден һәм медальләре, Мактау кәгазьләре– моның ачык дәлиле.

1418 көнгә сузылган дәһшәтле сугыш еллары авырлыгын үз җилкәләрендә татыган, олы тормыш юлы үткән хөрмәтле ветераннар – бертуган Василий һәм Семён Антиповлар үзләренең тормыш иптәшләре белән күпләргә үрнәк булырлык гаилә төзиләр, балалар үстерәләр. Алар безне, оныкларын да, авырлыклар килгәндә сагылып төшмәскә, сабыр-чыдам булырга өйрәттеләр. Без үзебезнең бабаларыбыз белән чиксез горурланабыз һәм аларның батырлыгын, тиңдәшсез хезмәтен онытмыйбыз!

*Тимофеева Татьяна*
*(7112 нче төркем)*

# Студент тормышы




2017 нче ел. Ят шәһәр. Башка мөхит. Авылдан килгән кыз югалып калмасмы? Шәһәр шаукымы аны "йотмасмы"?

Йотмады. Укуда да артта калмадым, дусларның да ышанычлыларын сайладым: охшаш омтылышлар, уртак кызыксынулар безне бергә җыйды.

Кешеләргә тиз ачыла алмыйм – табигатем шундый. Беренче уку елымны бераз күләгәдә үткәрсәм, икенче курстан ныклап фәнни хезмәткә кереп киттем: бер-бер артлы мәкаләләр язылды. Өченче курстан Илзирә белән татар филологиясе кафедрасы студентлары чыгарган "Шәкерт" газетасын җитәкләдек. Күп кенә дусларны нәкъ менә "Шәкерт"тә таптым. Газетага мәгълүмат туплау студентларны гына түгел, ә студент-мөгаллим бәйләнешен ныгытты.

Күңел өчен генә булса да, шигырьләр язгалыйм. Мәктәп елларында ук "Каурый каләм" конкурсында катнашып, Алабуга институты белән таныштым. Беренче шигырьләрем "Шәкерт"тә урын алды. Әкренләп "Мәйдан"га үрмәләдем. Биредә минем "Елмайдың да мине әсир иттең", "Әниемнең күңел яктысы", "Һәркемнең үз байлыгы", "Көрешергә өмет күңелдә", "Мине җиргә күзләр бүләк иткән" шигырьләрем дөньяга чыкты.

«Фән җилкәннәре» минем студент кына түгел, укытучы буларак үсүемә, чыныгуыма этәргеч булды. Фәнни-әдәби түгәрәк старостасы булып башлаган беренче адымнарым әкренләп ныгый барды. Биредә түгәрәкнең җитәкчесе Гомәр Филгиз улы Даутовның ярдәме, авыр вакытта терәк була белүен искәртү зарур. Җаваплы да, шул ук вакытта күңелле вакыйгаларга бай 5 елны Гомәр абый белән аңлашып эшләдек. Мин, студент буларак, һәр эшкә җаваплы карасам, Гомәр абый һәрдаим үсендерепторды.

Әллә шигъри җанлы булганга, әдәби очрашулар күңелгә аеруча якын. 21 нче март көнне "Китап" радиосы үткәргән очрашудан канатланып кайттым. Бер кичкә булса да язучылар белән бер көймәдә булдым. Шигырь сөйләргә чыккандагы шатлык катыш борчуымны искә алам да, янә шул хисләрне кичергәндәй булам.

Студентлар өчен әдәби мөхит тудырган кафедрабызга, һәрдаим ярдәмгә омтылган мөгаллимнәребезгә чиксез рәхмәтлемен. Шул чакта гына мин ачылып иҗат итәм һәм итәчәкмен.

*Евдокимова Алёна, 7112 төркем*

Безнең адрес: 423600, Алабуга, Казан урамы, 89, татар филология кафедрасы (53 бүлмә).
Баш һәм техник мөхәррир: Мөхәммәтҗанова Илзирә
Электрон адрес: tatar.kafedrasy.2020@mail.ru
Тираж: 500 данә.
6+